ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 2 пунктта «җирлекнең яисә шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектларын» сүзләрен «җирле әһәмияттәге объектларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 пунктта «җирлекнең яисә шәһәр округының функциональ зоналары» сүзләрен «функциональ зоналар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлешнең 1 пунктында «җирлекнең, шәһәр округының урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларының» сүзләрен «урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 өлештә:

а) 1 пунктның беренче абзацында «җирлекнең, шәһәр округының» сүзләрен төшереп калдырырга, «планлаштырылучы җирле әһәмияттәге объектлары» сүзләрен «планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) $4^{1}$ өлештә «җирлек яисә шәһәр округы составына керүче» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 66-ТРЗ